КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 сентябрь г.Казань № 687

«Өстәмә һөнәри белем бирү буенча мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, халыкның барлык катламнары өчен алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Өстәмә һөнәри белем бирү буенча мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 ел, 16 апрель, 291 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин